Л.Ф.Җамалиева,
Казан

# Г.Ибраһимовның “Татар хатыны ниләр күрми” әсәрендә туй йоласының әдәби чагылышы

Халык авыз иҗаты – әдәбиятның чишмә башы. Татар фольклоры һәм әдәбияты бәйләнешларын өйрәнү эше якынча чирек гасыр чамасы элек башланган булса (1), соңгы елларда бу мәсьәлә тагын көн тәртибенә күтәрелде (2; 4). Г.Ибраһимов иҗаты да бу юнәлештә инде тирәнтен өйрәнелгән. Шундый хезмәтләрнең берсе – фольклорчы галимә А.Садекова тарафыннан язылган “Фольклор в эстетике Галимджана Ибрагимова” дип аталган монография (3).

Г.Ибраһимовның “Татар хатыны ниләр күрми” әсәре XX гасыр башында уздырылган никах туе йоласының гаҗәеп тулы һәм җанлы чагылышы белән игътибарны җәлеп итте. Гомумән алганда, гаилә тормышы белән бәйле йола иҗатында өйләнешү– никах туена бәйле йолалар һәм поэтик әсәрләр үзәк урынны алып торалар. Чөнки өйләнешү – кеше тормышының иң җаваплы һәм күркәм чоры, кешенең мөстәкыйль тормышка аяк баскан вакыты. “Туй – барыннан да элек билгеле бер хуҗалык акты: гаилә, хуҗалыкка яңа әгъза кабул итү – эшче һәм нәсел үрчетүне максат итеп куя. Димәк, туй – экономик хаҗәтлек факторы булып тора. Шуңа күрә туй поэзиясенең һәрбер төрендә менә шул як чагылыш таба. Алай гына да түгел, кабиләчелек, ыручылык чорында бер төркемнең (гаиләнең) ныгуы, үрчүе дошман төркемдә (гаиләдә) ачу, көнчелек тудыра. Шуңа күрә туй үткәрү, уңышлы ярәшү (никах) турында реаль хәстәрлек күрү өстенә, кияү белән кәләшкә, туганлашкан гаиләләргә дошман көчләрдән (явыз рухлардан һәм үз өй-йорт рухларыннан һ.б.) саклану чараларын күрергә кирәк була. Болар өстенә яңа өйләнешкәннәрнең матур киләчәген булдыру, хуҗалыгын ныгыту, мал-туарын, нәселен үрчетү мәсьәләләре дә килеп баса. Менә шуларны искә алганда традицион туйларның һәртөрле ышану-табынуларга бай булуы бик табигый күзаллана (7,10).

Гасырлар дәвамында никах туеның төрле йола-гадәтләре формалашкан. “Урынына-ягына, авылына-тирәлегенә карап, туйлар төрле җирдә төрлечәрәк үткән... Бу тарих һәм көнкүреш, җирле шартлар һәм тирә-юньдәге элемтә-йогынтылар белән бәйләнгән табигый бер хәл” (5, 11). Әмма халкыбызның туй йолаларында һәм туй поэзиясендә барлык этник төркемнәр һәм төбәкләр өчен дә уртак катламнар бар. Бу катламнар туй йоласының һәм иҗатының борынгыдан килгән тотрыклы табигатен һәм гомуми милли йөзен билгелиләр. Туй йолаларының төп мәгънәсе кайсы халыкта, кайсы чорда булуга карамастан – яңа гаиләне, яңа союзны булдыру, аны рәсмиләштерү, тануга кайтып кала. Төп юнәлеше һәм составы исә бер йорттан икенче йортка кыз (кәләш) тапшыру, булачак ирнең йортына озатудан тора. Октябрь революциясенә кадәр татарларда өйләнешүнең өч төре булуы билгеле: 1) яучы җибәрү, кодалау аша; 2)кызның ата-ана рөхсәтеннән башка, үз теләге белән сөйгәне белән кушылуы (ябышып чыгу); 3) кызны урлап алып китеп өйләнү. Соңгы ике очракта туй йолалары үтәлми кала. Ә менә яучылау (килешеп сөйләшү) аша никахлашуга бәйле туй йолалары рухи һәм физик яктан сәламәт, матди ягы тәэмин ителгән яшь гаилә булдыруны тәэмин итүгә корылган, шуңа күрә туй йоласы этапларын бөтен ваклыклары белән үтәүне күздә тота һәм гасырлар дәвамында саклана.

Г.Ибраһимовның “Татар хатыны ниләр күрми” әсәре “Бер атна эчендә кызга ике яучы килде” (6:225) дигән җөмлә белән башланып китә. Шушы җөмлә укучыны әсәр герое булган кыз тормышында булачак кискен үзгәрешләргә әзерләп куя. Гадәттә, “кемнең кызын сорату мәсьәләсе хәл ителгәч, егет ягы дәрәҗәлерәк кешене яучы (башкода, димче) итеп билгели. Гадәттә, туган тиешле, телгә оста, дипломат кеше билгеләнә” (7:11) . Гөлбануга килгән яучыларның берсен этисе тиз генә борып җибәрсә дә, Шибай кантуннан килгәнен бора алмый. Әсәрдәге вакыйгалар Нурый карт йортында туйга әзерлекне тасвирлау белән дәвам итә.

Автор хуҗаларның туйга чакырылган кунакларны, аеруча кодаларны бик дулкынланып көтүләре турында яза. Башкодалар туйга беренче чанада

киләләр. Аларны кызның әти-әнисе каршылый. Кияүнең кан-кардәшләрен кызның бертуган абый-җиңгәләре каршы ала. Күчтәнәчкә дигән туй ашларын аерым чанада алып килүгә дә игътибар бирелә (6, 247).

Никах туе табынындагы милли ризыкларны сурәтләүгә дә зур урын бирелә. Татар халык ашлары искиткеч тәмле. Ә инде мондый төр мәҗлесләрдә ризык әзерләүгә аеруча зур игътибар бирелә. Чөнки туй ашлары кодалар тарафыннан да бәяләнә. Кодалар үзләре дә туйга бик зурлап килгәннәр. Өлкән кода Шибай, Әфтәх, Алтынбай кодаларның бүләк ашларын исемләп, табынга чыгарып күрсәтәләр һәм кунакларга бүлеп бирәләр. “Арада иң шәбе, әлбәттә, Шибайныкы булды. Аның майлары тулышып торганике симез казы белән симез күркәсе, өсләренә каклар, җимешләр сибеп пешерелгән дүрт зур ләвәш күмәче, кечкенә дүрткел тау кебек торган, өсте, читләре кәнфит белән чәчәкләнгән зур ике баллы бавырсагы – тагын әллә ничаклы оста әзерләгән аш бүләкләре мәҗлеснең күзен уйнатты” (6, 249). Туйдан соң кәләшнең иптәш кызларын җыеп, аларга кияү бүләкләре өләшә торган бүләк чәе табынында да, кызны кияү йортына төшерү һәм андагы мәҗлестә дә туй өчен пешерелә торган ризыкларны сурәтләүгә дә аерым игътибар ителә. Бүгенге көндә уздырыла торган туйларда борынгы йолаларның бик күбесе онытылса да, кода-кодагыйларның туй табынына махсус ризыклар пешереп алып килүләре, аларны, зурлап, кунакларга күрсәтү һәм һәрберсенә авыз иттерү сакланып калган.

Кияү килү күренешен сурәтләү дә игътибарга лаек. Закир туры кыз йортына түгел, ә өндәүче Хәбип йортына төшә. “Никах укылганчы шул өндәүче йортында калачак, аннан кыз катына киләчәк” (6, 250). Өндәүче –ул туйга кунакларны чакыру өчен махсус билгеләнеп куелган кеше. Фольклор материалы нигезендә диалекталь үзенчәлекләрне өйрәнүче галимә Ф.Баязитова өндәүче сүзенең Башкортстан татарларында бик актив булуын билгеләп үтә (10, 221).

Кияү кыз янына кияү егетләре белән килә. Бик шаулап, мылтыктан атып киләләр (6, 254). Р.Мөхәммәтҗанов моны “кияү килгәндә яки килен

төшергәндә мылтыктан ату борынгыдан килгән ышану, явыз көчләрне куарга яки куркытырга мөмкин булган нәфрәт уятучы магия” дип саный (7, 28). Кияү килгәндә мылтыктан һавага ату күренеше Мордовиядә яшәүче татарларда, төгәлрәк әйткәндә Белозерьеда бүгенге көнгә кадәр сакланып калган.

“Ишек бавы” җырлары туй иҗатында аерым бер төркем тәшкил итә. “Никах укылганнан соң шул ук көндә, яисә күпмедер вакыт үткәннән соң, кичен кояш баегач, кияү үзенең дуслары (кияү егетләре) белән пар атта яки тройкада кыз янына килә торган булган. Кыз янына келәткә яки ак өйгә үтү өчен, кияүдән ишек хакы түләве таләп ителгән. “Ишек бавы” җырлары әнә шундый чакта, кыз янына керер алдыннан башкарылганнар” (8:88). Әсәрдә “Ишек бавы” җыр текстлары үзләре бирелмәсә дә, кияү килү, ишек бавы тотучы балаларның бүләк сорау күренешләре бик халыкчан итеп сурәтләнә: “Тышкы яктан малайлар һаман киреләнделәр: “Җизни! Ишек бавы бер акча, безнең апай мең акча!”– дип, кулларына бирелгән егермешәр тиенлек көмешкә риза булмадылар, тыш яктан ишек бавын җибәрми тордылар. Кияү тагын берәр көмеш салды, балалар һаман усалландылар, шул ук сүзне кабатладылар: “Җизни! Ишек бавы бер акча, безнең апай мең акча!”

Егет өченче тапкыр бирде. Малайлар шатлыктан сикерешеп чаптылар. Кияү ишек бавын тартып җибәрде, эчтән кунак килен киләне ычкындырды” (6, 271).

Туй буласы йорт, бигрәк тә кияү керәсе бүлмә, гадәттә кияү келәте, ә бу очракта түбән оч Хәмит йорты турында укыганда да авторның оста рәссам кебек эш итүенә сокланмый мөмкин түгел. Алар укучыны шул чордагы татар авылларындагы яшәү шартлары, йорт җиһазлары, бүлмә бизәлеше белән таныштыру өчен махсус эшләнгән кебек (6, 269). Кунак килен Мәрхәбә белән матур җиңги Мәфтуха “кызның бирнәләре, эшәнчекләре белән тулы ак калайлы зур ике сандык”тан чыккан “киҗеле сөлгеләр, чигүле намазлыклар белән өйнең бөтен ялангач стеналарын бизәп бетерәләр” (6, 269). Чыннан да, әсәрне укып, ул чорда кызның бирнәсен әзерләүгә күпме вакыт, көч һәм акча

сарыф ителүен күрергә мөмкин: “Гөлбану, ундүрт яшеннән алып, һәр яз берничә ай киндер сукты, үзенә, булачак киявенә сөлгеләр, ашъяулыклар, күлмәкләр, чаршаулар, чыбылдыклар әзерләде... Менә шулай итеп, унҗиде яшенә кергәндә, кызның эшәнчеге, бирнәсе бик бай булып әзерләнеп җитте” (6, 272). Әмма шушы бай бирнә һәм кыз өчен түләнгән мәһәр Гөлбануның бәхетсезлегенә дә сәбәп булып тора. Кызның кайнана йортында коточкыч шартларда яшәвен белсә дә, әтисе Нурый карт аның ирен ташлап кайтуына каршы була. Чөнки ир аермаса, хатын китә алмый. Әгәр китсә, аның барлык әйбере ир кулында калачак. Фәтхия мәһәр, бирнә дип, бердәнбер кызын ут эчендә яндырырга теләмәсә дә, ире Нурый: “Өч йөз сум мәһәрне ничек ташлап китәсең” дип, кызны кайтартмый.

Туйга кияү ягыннан килгән кунакларны хөрмәтләү, аларны кәләш гаиләсендә генә түгел, туй күтәрешүчеләрдә дә кунак итү, кодалар җигеп килгән атларны саклау күренешләре дә әсәрдә бик җанлы итеп тасвирланган. Бик тырышып саклауларына да карамастан, кодалар атының койрыгын кисәләр. Дөрес, беленер-беленмәс кенә. Әмма бу инде хурлык булып санала. Алга таба Гөлбануның “әрем тел”ле кайнанасы тарафыннан киленне рәнҗетеп күп мәртәбәләр телгә алына.

Әсәрдә туй йоласының бөтен өлешләре дип әйтерлек бик җентекле рәвештә тасвирланган, кәләшне иптәш кызлары белән кызлык гомере үткән яланнардан саубуллаштырып кайтару да, кияү йортына озата бару да һ.б. Кияү килгәндә аш күчтәнәч туй ашларының аерым арбада килүен күрсәк, килен төшергәндә, алдан киленле көймә, ирле-хатынлы кунак арчилар, алардан соң сандыкның аерым арбада баруына игътибар иттек. Бик сирәк очрый торган күренеш – яшь егет-җилкенчәкнең бер-берсен сөзмә белән буяп, аклап, киленне каршы алуы сурәтләнгән урыннар, шушы чорда гамәлдә булган халык йолаларын бөтен нечкәлекләре белән күз алдына китерергә ярдәм итә.

Автор Гөлбануның беренче мәртәбә суга баруын да җентекләп тасвирлый (6, 316). Башкорт халык авыз иҗатын киң планда тикшергән

галим С.Галин фикеренчә: “... бу йолада табигать культы –суга табынуны, шушы йолага ниндидер магик мәгънә салынганлыгын күрмәү мөмкин түгел”. Бер үк вакытта бу йоланың икенче – психологик ягы да булган, күрәсең. Һәрхәлдә, су юлы әле генә озатылып төшкән киленгә бераз тынычланып алырга, содгы тапкыр булса да үзенең тиңнәре белән йөреп кайтырга мөмкинлек биргән (9, 28-29).

Туй никадәр генә матур булмасын, ул бик тиз уза. Кияү йортына төшкәннең беренче көненнән үк, Гөлбану, ишле гаиләнең бик күп эшләрен үз җилкәсенә алырга мәҗбүр була. Кайнатасы Шибай үлгәннән соң кәләшнең тормышы бик авырлаша. Иренең кыйнаулары, кайнананың явызлыгы, игезәк балаларның үлүе Гөлбануны соңгы чиккә җиткерә – ул суга ташланып үлә. Әсәрнең халык иҗаты белән бәйләнешен өйрәнгән галимә А.Садекова әсәрнең сюжеты традицион бәетләрне кабатлый дип саный (3, 64).

Нәтиҗә ясап әйткәндә, Г.Ибраһимов тарафыннан халыкның гореф-гадәтләрен, этнографиясен тирәнтен өйрәнеп язылган “Татар хатыны ниләр күрми” әсәрен укып, XIX гасыр азагы  XX гасыр башында уздырылган туй йоласының эчтәлеге, аның аерым этаплары хакында бик тулы һәм кызыклы мәгълүмат алырга мөмкин.

Искәрмәләр:


1. Ахметова Ф. О некоторых особенностях использования фольклора в современной татарской прозе // Вопросы татарского языка и литературы. : Кн. 4. // Ф.Ахметова. – Казань, 1969. С. 81-87. , Галиуллин Т. Илһам чишмәләре // Т.Галиуллин. – Казан: Тат.кит. нәшр., 1988.
2. Урманчеев Ф. Дастаннарга лаек замана. Борынгы фольклор һәм хәзерге поэзия // Ф.Урманчеев. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1990., Урманчеев Ф. Волшебный клубок. Муса Джалиль и народное творчество // Ф.Урманчеев. – Тат.кн. издат., 1995., Урманчеев Ф. Борынгы миф һәм бүгенге шигырь. Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллин шигърияте нә бер караш // Ф.Урманчеев. – Казан:

Мәгариф, 2002., Урманчеев Ф. Роберт Миңнуллин: шигъри осталык серләре // Ф.Урманчеев. – Казан: Мәгариф, 2005.

3. Садекова А. Фольклор в эстетике Галимджана Ибрагимова / А.Садекова. – Казань, 1995.
4. Надиров И. Шифалы чишмә (Татар фольклорының мәдәният тарихында тоткан урыны турында берничә сүз) // Фәнни эзләнүләр юлында// И.Надиров. – Казан: Фикер, 2000. – Б. 218-234.
5. Надиров И. Татар халкының йола поэзиясе, уен җырлары, бию такмаклары // Татар халык иҗаты. Йола һәм уен җырлары / И.Надиров. – Казан: Тат.кит. нәшр., 1980.
6. Ибраһимов Г. Татар хатыны ниләр күрми. Әсәрләр. Сигез томда. 1 том. Хикәяләр (1907-1929) / Г.Ибраһимов. – Казан: Татар. кит.нәшр., 1974.
7. Мөхәммәтҗанов Р. Башкортстан Ык буе татарларының йола иҗаты (Туй поэзиясе) “Татар халык иҗаты” курсы буенча читтән торып укучы студентлар өчен уку әсбабы / Р.Мөхәммәтҗанов. – Уфа, 1977.
8. Бакиров М. Туй йолалары һәм аларга бәйләнешле поэтик әсәрләр / М.Бакиров. – Мирас, 1998. – № 4. – Б. 81-95.
9. Галин С. Йыр. Такмак. Сеңләү / Башкорт халык ижады. Йырзар. Икенсе китап / С.Галин. – Өфө: Башкортстан китап нәшрияте, 1977.
10. Баязитова Ф.Г.Ибраһимов әсәрләрендә этнографизмнар // Г.Ибраһимов һәм хәзерге заман: Тууына 115 ел тулуга багышланган фәнни конференция материаллары / Ф.Баязитова. – Казан: Фикер, 2002. –Б. 218-225.